РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 21 мае № 21

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәр Советының муниципаль контроль өлкәсендәге кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының «Контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан кулланыла торган документларның типик рәвешләре турында» 2021 елның 31 мартындагы 151 номерлы боерыгын исәпкә алып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары (алга таба - Нигезләмә) белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктындагы 4.2.1 пунктчасының җиденче абзацында «әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә» сүзләрен «Контроль органы раслаган рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

4.10.3 пунктының өченче абзацында «әлеге нигезләмәнең 5 нче кушымтасы формасы буенча» сүзләрен «Контроль органы раслаган форма буенча» сүзләренә алмаштырырга;

нигезләмәдәге 3-5 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 60 номерлы карары (алга таба - Нигезләмә) белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктындагы 4.2.1 пунктчасының җиденче абзацында «әлеге нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендә» сүзләрен «Контроль органы раслаган рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

4.9.3 пунктының өченче абзацында «әлеге нигезләмәнең 5 нче кушымтасы формасы буенча» сүзләрен «Контроль органы тарафыннан расланган рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

нигезләмәдәге 3-5 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын башкаручы, Мэр урынбасары — М.В. Камелина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД НИЖНЕКАМСК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН